**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 03.02.2020** **№ 164**

**Татарстан Республикасы Биектау мунииипаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 нче елның 6 нчы октябреннән 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы» Федераль законы, 1996 нчы елның 12 нче январеннән 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законы, 2007 нче елның 18 нче маеннан 196 нчы номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, 2020 нче елның 29 нчы январеннән 61 нче номерлы «2020 нче елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турындагы» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 нче елның 1 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1 нче Кушымта һәм 2 нче Кушымта нигезендә, 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 нчы елның 31 нче январеннән 190 нчы номерлы «Җирләү буенча хезмәтләрне гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтүнең бәяләрен раслау турындагы» карары 2019 нчы елның 1 нче февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында:. http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресында урнаштырып, халыкка җиткерергә;
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 нче елның 3 нче
февраленнән
164 нче номерлы
карарына
1 нче Кушымта

2020 нче елның 1 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
БӘЯСЕ

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *( сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | түләүсез |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка кирәк-яраклар тапшыру һәм китерү | 3571,52 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка китерү | 812,43 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1740,91 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 нче елның 3
нче февраленнән 164 нче
номерлы карарына
2 нче кушымта

2020 нче елның 1 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
БӘЯСЕ

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *( сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | түләүсез |
| 2. Кәфенләү | 464,25 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар тапшыру һәм китерү | 3107,27 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 812,43 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1740,91 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |